ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
13.12.2024

КАРАР
№ 1514

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында"01.03.2019 ел, № 224 карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында" 21.12.2021 № 414-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 01.03.2019 ел, № 224 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин